| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 г.Зеленодольск № 148

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында » 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге«Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы Федераль законның 23.14 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пункты, 2020 елның 31 июлендәге«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карар **кабул итте**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы карары (алга таба - Нигезләмә) белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 4 бүлеген түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлеше буенча Контроль орган карарларына, муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү

4.1. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлеше буенча Башкарма комитет карарларына, муниципаль

контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлеге билгеләгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

4.2. Башкарма комитет карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) бары тик судка кадәр шикаять белдерелгәннән соң гына шикаять белдерелергә мөмкин, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмаган гражданнар тарафыннан судка шикаять бирү очракларыннан тыш.

4.3. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрне үтәү буенча муниципаль контроль кысаларында контрольдә торучы затлар , хокук һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган, алар фикеренчә, судка кадәр шикаять белдерергә хокуклы:

а) контроль чаралар уздыру турындагы карарларна;

б) контроль чаралар актларына;

в) контроль чаралар кысаларында Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына).

4.4. Шикаять Башкарма комитетка дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып, контрольдә торучы зат тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять биргәндә граждан тарафыннан ул гади электрон имза йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьләр, дәүләт яисә башка саклanучы сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланмыйча гына кәгазь саклагычта контрольдә торучы зат тарафыннан тапшырыла.

4.5. Шикаять Башкарма комитет карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала.

4.6. Шикаять Башкарма комитет карарына , аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) контрольдә торучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенечнамәсе буенча әлеге срок Башкарма комитет тарафыннан яңадан алынырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне кабат шул ук нигезләр буенча җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә Башкарма комитетының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

4.7. Башкарма комитет шикаятьне теркәгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карар кабул итә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турында үтенечнамә буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә шикаять биргән затка җибәрелә.

4.8. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган Башкарма комитет атамасы, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), яшәү урыны (эшчәнлек алып бару урыны) турында белешмәләр, яисә мөрәҗәгать итүче- оешма атамасы, әлеге оешманың урнашу урыны турында белешмәләр, йә шикаять бирүче затның ышанычнамә реквизитлары, фамилиясе, исеме, атасының исеме( булса), шикаятьне карау вакытында үзара эшчәнлекне башкаруның теләгән ысулы һәм аның буенча карар алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган шикаять белдерелә торган Башкарма комитет карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле(гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетның һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән нигезләре һәм дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче үзенең дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре;

6) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса, шикаять бирелә торган контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрында контроль чарасының исәп номеры.

Шикаятьтә Контроль органы вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата цензурасыз яисә хурлый торган сүзләр, янаулар булырга тиеш түгел.

Шикаятьне бирү «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша контрольдә торучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан, аңа тиешле хокукны биргән очракта, гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның җәмәгать вәкиленең, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең шикаять предметына караган позициясе дә кушылырга мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, аның җәмәгать вәкиле, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил позициясенә җавап контроль орган тарафыннан шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

4.9. Башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) шикаятьне алган вакыттан алып биш эш көне эчендә шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә, әгәр:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы тәмамланганнан соң бирелсә һәм аны яңадан алу яисә шикаять бирүнең югалган срогын кабат яңарту турында үтенечнамә булмаса;

2) шикаять бирүгә җибәрелгән срокны яңарту турындагы үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тартса;

3) шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны биргән заттан шикаятьне кире алу турында гариза керсә;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары булса;

5) элек Башкарма комитетта шул ук контрольдә торучы заттан, шул ук нигезләр буенча башка шикаять бирелгән булса;

6) шикаятьтә контроль орган вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының яшәү, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә цензурасыз яисә хурлый торган сүзләр булса;

7) элек әлеге контрольдә торучы затның шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгара торган шул ук предмет буенча шикаятьне караудан баш тартса һәм яңа дәлилләр яисә нигезләр китерелмәсә;

8) шикаять тиешле булмаган Контроль органга тапшырылган;

9) Россия Федерациясе законнары нигезендә контроль орган карарларына шикаять белдерү буенча суд тәртибе генә каралган.

Әлеге пунктның 3 - 8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм аның вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тарафыннан шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

4.10. Шикаятьне карауга вәкаләтле вәкил Контроль органының вазыйфаи заты шикаятьне караганда контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасыннан файдалана, моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми.

Башкарма комитет контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә карата судка кадәр шикаять бирү ярдәмче системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләрне тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, Россия Федерациясенең закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге ярдәмче системасыннан файдаланмыйча, Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.11. Шикаять Башкарма комитет тарафыннан теркәлгәннән соң егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Күрсәтелгән срок егерме эш көненә, түбәндәге аерым очракларда озайтылырга мөмкин:

1) шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча хезмәт тикшерүенә шикаять белдерелә торган вазыйфаи зат гамәлләре (гамәл кылмавына) карата

үткәрелсә;

2) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затның нигезле сәбәп белән (авыру, отпуск, командировка) булмау;

3) башка органнар карамагындагы белешмәләрне алу таләп ителсә.

4.12. Башкарма комитет шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратырга хокуклы.

Контрольдә тотылучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы темасы өстәмә мәгълүмат бирү турында сорату һәм шикаять предметына караган документлар җибәрелгәннән алып, аларны Башкарма комитет алган вакытка кадәр туктатып торыла, әмма сорату җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артмаска тиеш.

Контрольдә торучы заттан өстәмә мәгълүмат һәм шикаять предметына караган документларны алмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

Шикаятьне биргән контрольдә торучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнчегә кадәр үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

4.13. Вазыйфаи затның карары һәм (яки) гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирү буенча кабул ителгән карарның законлылыгын һәм нигезлелеген раслау һәм (яки) гамәл кылуның (гамәл кылмау) бурычы Башкарма комитетка йөкләнә,

4.14. Шикаятьне карау йомгаклары буенча Башкарма комитетының контроль органы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыра;

2) Башкарма комитетының карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгара;

3) Башкарма комитет карарын тулысынча гамәлдән чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Башкарма комитетының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында, карар чыгара.

4.15. Кабул ителгән карарны нигезли торган Башкарма комитет карары кабул ителгән карар, аны үтәү срогы һәм тәртибе Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдә торучы затның шәхси кабинетында, кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, урнаштырыла.

Дәүләт яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау йомгаклары буенча Башкарма комитетның карары, Россия Федерациясенең закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контрольдә

торучы затка кәгазь саклагычта, ул кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

1.2. Нигезләмәнең 5.2 пунктындагы 5 бүлегендә «(1нче кушымта)» сүзләрен өстәргә.

1.3. Нигезләмәне әлеге карарга 1нче кушымтада каралганча «Контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, индикатив күрсәткечләре» 1 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарын «Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 2 нче кушымта нигезендә әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә өстәргә.

3. Нигезләмәнең 4 бүлеге 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

«Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта»
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 148 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Контроль төренең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан к әһәмияте , индикатив күрсәткечләре**

1.Төп күрсәткечләр һәм аларның әһәмияте:
Мәҗбүри таләпләрне бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше-70%
Чираттагы календарь елга планлы контроль чараларын уздыру планын үтәү проценты -100%
Контроль чаралар уздырганда муниципаль контроль органы һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата нигезле шикаятьләр проценты-0%
Контроль чараларның үткәрелмәгән нәтиҗәләре процентлары 0%
Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча бозулар ачыкланган, әмма тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән өлеше-5%.
Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты- 95%
Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә гамәлдән чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми саныннан өлеше, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 2.7 һәм 2.9 статьялары нигезендә гамәлдәнчыгарылган карарлардан тыш - 0%.
2. Федераль дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) индикатив күрсәткечләре исемлеге

1) хисап чорында уздырылган планлы контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен ачыклау яисә мондый параметрлардан, хисап чорыннан контроль объектын тайпылдыру нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында үткәрелгән үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән һәр контроль (күзәтчелек) чаралар төре буенча үзара хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга һич тә ярамау турында кисәтүләр саны;

9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында прокуратура органнары тарфыннан килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына контрольдә тотуның исәпкә алынган объектларының гомуми саны;

15) риск категорияләренә кертелгән контроль объектларының һәр категориясе буенча хисап чоры ахырына исәпкә алынган объектларының саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә торучы затлар саны;

17) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылган исәпкә алынган контрольдә торучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә торучы затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогын бозган шикаятьләрнең саны;

20) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмауларын) гамәлдә түгел дип тану турында карар кабул ителгән контрольдә торучы затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән шикаять белдерү турында дәгъва гаризалары саны ;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас рәвештә бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны .

«Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2021 елның 17 декабрендәге
129 номерлы карарына
2 нче кушымта»
Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2022 елның 24 мартындагы
148 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль к контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу риск индикаторлары исемлеге**

Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу риск индикаторлары:

Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль бозу билгеләрен ачыклау;

контроль органга дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, иҗтимагый берләшмәләрдән, гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне бозу һәм закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы булу турында мәгълүмат керү;

контроль чара нәтиҗәләре буенча бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең билгеләнгән срокта үтәлеше турында контроль органында мәгълүмат булмау.